Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
К А Р А Р Ы

29 апрель 2016 ел №64

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы территориясендә
җир участоклары бирү нормалары турында

Татарстан Республикасы Җир кодексы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының түбәндәге карарлары үз көчен югалтты дип танырга:

- **2009 елның 19 февралендәге № 311** ”Әлмәт муниципаль районы территориясендә бирелүче җир участокларының җир күләмнәре турында”;

- **2010 елның 26 маендагы № 394** “2009 елның 19 февралендәге № 311 нче ”Әлмәт муниципаль районы территориясендә бирелүче җир участокларының җир күләмнәре турында” Әлмәт муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында;

- **2014 елның 3 июлендәге № 389** “2009 елның 19 февралендәге № 311 нче ”Әлмәт муниципаль районы территориясендә бирелүче җир участокларының җир күләмнәре турында” Әлмәт муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында;

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы территориясендә гражданнарга шәхси милек итеп һәм бушлай җир участоклары бирүнең түбәндәге нормаларын билгеләргә:

- шәхси торак төзелеш өчен:
шәһәр һәм авыл җирлекләрендә 0,04 –0,50 га кадәр,
- шәхси йорт яны хуҗалыгы алып бару өчен:
авыл җирлеге территориясендә – 0,10 га дан 0,50 га кадәр.

3. Район Советы аппараты юридик бүлегенә (Ә.Б.Ханнанова) әлеге карарны “Альметьевский вестник” газетасында бастырып чыгарырга, “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

4.Әлеге карар рәсми чыганакларда бастырылганнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәт муниципаль районы Советының икътисадый үсеш, торак–коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Ш.К.Закиров) йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.Р.Хәйруллин